**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2016 Балык Бистәсе штп. № 145пи

Төзелеш өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 3 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 21.06.2016 ел, №96пи «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» гы карары нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 4 августындагы 201пи номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 июлендәге 107пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге»графасының 2.6 пунктында түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

Әлеге пунктның 1, 2 һәм 3 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) бүлек тарафыннан дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмаларда әлеге документлар карамагында булган оешмаларда төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына.»;

жиденче-тугызынчы абзацларны сигезенче – унынчы абзацлар дип санарга;

б) 3.4.1 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 4 августындагы 201пи номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 июлендәге 107пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Стандарт таләпләренең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Әлеге пунктта каралган документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) бүлегенең ведомствоара гарызнамәләре буенча тиешле ведомствоара гарызнамә алынган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан бирелә.»

б)3.4.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар тиешле ведомствоара гарызнамә органга яисә документны һәм мәгълүматны бирүче оешмага кергән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин